КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь

г.Казань

№ 1438

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 июль, 665 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 22 июль, 705 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен сәнгать-анимация басмаларын бастырып чыгаруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

18 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткечләре (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы җыелма командасының (вәкилләренең) төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык чемпионатларында һәм мәгариф һәм фән өлкәсендәге башка конкурсларда катнашуын оештырып, мәгариф һәм фән өлкәсендә чараларны (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук башка чаралар) оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 август, 689 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 август, 892 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы җыелма командасының (вәкилләренең) төрле дәрәҗәдәге һөнәри осталык чемпионатларында һәм мәгариф һәм фән өлкәсендәге башка конкурсларда катнашуын оештырып, мәгариф һәм фән өлкәсендә чараларны (конференцияләр, киңәшмәләр, олимпиадалар, симпозиумнар, съездлар, белем бирү сменалары, күргәзмәләр, конкурслар, һөнәри осталык чемпионатлары, шулай ук башка чаралар) оештыруга һәм уздыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

9 пунктның бишенче абзацында «30 календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «бишенче календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 октябрь, 1060 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 10 август, 785 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Дәүләт аккредитациясе булган төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы шәхси мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү, шәхси гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшмәкәрләр тарафыннан

мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү» сүзләрен «күрсәтелгән» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

3 пунктның икенче абзацында «күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү» сүзләрен «мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «бирү буенча хезмәтләр күрсәтүче» сүзләрен «мәгариф программаларын гамәлгә ашыручы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта «күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү» сүзләрен «бирү» сүзенә алмаштырырга;

9 пунктның өченче абзацында «30 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләрен «10 нчы календарь көннән иртәрәк» сүзләренә алмаштырырга;

16 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткечләре (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

17 пунктта:

беренче абзацта «күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү» сүзләрен «мәгариф программаларын гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруда катнашучы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнары;»;

23 пунктта:

икенче абзацта «мәктәпкәчә белем бирү хезмәте алган тәрбияләнүчеләргә,» сүзләрен «мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучыларга» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «, башлангыч гомуми белем алган» сүзләрен «башлангыч гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «, төп гомуми белем бирү хезмәте алган» сүзләрен «төп гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «урта гомуми белем бирү хезмәте алган» сүзләрен «урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары

буенча чемпионатларга әзерләү өлешендә устав эшчәнлеген, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыруны финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 2 август, 747 нче карары белән расланган Татарстан Республикасыннан катнашучыларны төрле дәрәҗәдәге «Ворлдскиллс» стандартлары буенча чемпионатларга әзерләү өлешендә устав эшчәнлеген, «Ворлдскиллс» стандартлары нигезендә чараларны оештыруны финанс белән тәэмин итүгә коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

9 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

20 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин